
Хәерле
көн !

# дәрес сәяхәт.



Тавышлана-җил түгел,

Канаты бар-кош түгел,

Һавада оча,


Болытлар коча.




G650
N650GA



# Кроссворд



1 Турыйсың, турыйсың, тураганда елыйсың.



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| 4 | | | | | | |
| 5 | | | | | | |
| 6 | | | | | | |

# 2 Үлән ашый, май ташый.



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | | | | | | |
| 4 | | | | | | |
| 5 | | | | | | |
| 6 | | | | | | |





3 Төнлә калка,

көндез ята.



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | А | Й | | | | |
| 4 | | | | | | |
| 5 | | | | | | |
| 6 | | | | | | |

4 Озын дөньяга килә.
Күзен саргаеп үлә.



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | А | Й | | | | |
| 4 | Я | Ф | Р | А | К | |
| 5 | | | | | | |
| 6 | | | | | | |

5 **Ак ашъяулык таптык,**

**Җир өстенә яптык.**



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | А | Й | | | | |
| 4 | Я | Ф | Р | А | К | |
| 5 | К | А | Р | | | |
| 6 | | | | | | |

6 **Көлтә-көлтә койрыгым,**

**Селки-селки барамын.**

**Кетәкләргә кереп мин**

**Тавык-чебеш аламын.**



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | А | Й | | | | |
| 4 | Я | Ф | Р | А | К | |
| 5 | К | А | Р | | | |
| 6 | | Т | Ө | Л | К | Е |



# Кроссворд

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | С | У | Г | А | Н |
| 2 | С | Ы | Е | Р | | |
| 3 | А | Й | | | | |
| 4 | Я | Ф | Р | А | К | |
| 5 | К | А | Р | | | |
| 6 | | Т | Ө | Л | К | Е |





Предметның билгесен белдереп, **НИНДИ?** , **КАЙСЫ?** сорауларына җавап биргән сүзләр **СЫЙФАТ** дип атала.

# Унөченче март .
# Сыйныф эше .
# Сайланма диктант .



# Сыйфатларны аерып яз.

Өстәл, зур, уйный,
кызыл, яза,
укучы,
татлы.



Зур ,

Кызыл,

Татлы.





# Төшеп калган хәрефләрне куй.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Я | М | | Л | Е | | |
| Б | А | | Л | Ы | | |
| Т | А | | Л | Ы | | |
| С | Ә | Л | | М | Ә | Т |
| | О | М | Ш | А | К | |



Л



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Я | М | Ь | Л | Е | | |
| Б | А | Л | Л | Ы | | |
| Т | А | Т | Л | Ы | | |
| С | Ә | Л | А | М | Ә | Т |
| Й | О | М | Ш | А | К | |



# Җырдагы сыйфатларны тап :

1 ***Туган*** телем нинди ***матур***,
***Эчтәлекле,ягымлы***.
Хәтерләтә табигатьне,
***Гүзәл***,***туган*** ягымны.



***Туган*** телем-***татар*** телем,
Тормышка **алтын** аскыч.
***Якты*** хыяллар артыннан
Менәргә **мәр-мәр** баскыч.





2 Гөлбакчага охшаган ул,
Чишмәләр агышына.
***Җәйге*** иртәдә сайраган
***Сандугач*** тавышына.



3 Әтием кебек ***көчле,горур***,
Энием сыман ***назлы.***
***Җылы*** ***кояш*** нурларыдай
Җанда уята язны.






PLUMERIA GARDENS

# Капма-каршы мәгънәле сыйфатларны тоташтыр :

| | |
|---|---|
| КИҢ | КЫСКА |
| ЯХШЫ | ЯЛКАУ |
| ЯКТЫ | ЭЧЕ |
| ОЗЫН | ПЫЧРАК |
| ТЫРЫШ | НАЧАР |
| ТАТЛЫ | КАРАҢГЫ |
| ЧИСТА | ТАР |



- Менә ( …) яз килде. ( …) кояш җирне җылыта. ( … ) карлар эриләр. Тамчылар тама. Урамнарда гөрләвекләр ага. Җылы яклардан (… ) кошлар кайта. Җирдә (… ) үлән күтәрелә. Агачлар яфрак яра.

- ( ямьле, җылы , ап-ак ,күчмә , яшел .)

- Менә ямьле яз килде. Җылы кояш җирне җылыта.Ап-ак карлар эриләр.Тамчылар тама. Урамнарда гөрләвекләр ага.Җылы яклардан күчмә кошлар кайта.Җирдә яшел үлән күтәрелә.Агачлар яфрак яра.







# Җөмләләрне әйтеп бетер :

- Шикәр ак , ә күмер ...
- Дәфтәр юка ,ә китап ...
- Чистай урамы киң ,ә Муса Җәлил урамы ...
- Әтинен сумкасы авыр,ә минеке ...
- Кичә көн болытлы иде ,ә бүген ...
- Идел елгасы киң ,ә Казансу ...



# Җөмләләр дөрес төзелгәнме?

1. Кышкы матур көндә без күлгә су коенырга киттек.
2. Кайнар яңгыр астында каз бәбкәләре күшегеп беткәннәр.
3. Бу сай елгада теплоходлар йөри.
4. Җәйге матур көндә без карлы таудан чана шуабыз.


www.postcard.ru

# Картинаны карагыз.Сыйфатлар кулланып җөмләләр төзегез.



и
т
а
п

*1 төркем*

*2 төркем*








# Тест :

1) Сыйфат нинди сүз төркеме?

а)предметнын билгесен белдерүче

б)предметны белдерүче;

2) Нинди? Кайсы? сорауларына нинди сүз төркеме җавап бирә?

а) исем

б) сыйфат;

3) Капма – каршы мәгънәле сүзне тап.

яңа-...

а) саран

б) иске

в) тәбәнәк

г) тырыш ;

4) Сыйфатларны билгеләгез :

а) куян в) мәктәп

б) матур г) татлы;

5) Артык сүзне тап :

а) матур в) өй

б) тыйнак г)яшел ;

6)Нинди?соравына җавап бирүче сүзне тап :

а) шагыйрь

б) табиб

в) тыйнак .





# САУ БУЛЫГЫЗ !

